**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ КИБӘХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**алтынчы утырыш дүртенче чакырылыш**

**КАРАРЫ**

**«12» март 2021 ел** **№ 17** **Югары Кибәхуҗа авылы**

Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 декабрендәге 124-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Теләче районы прокурорының 2021 елның 12 февралендәге 02-02-01-2021 номерлы протестын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 декабрендәге 124-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары

Кибәхуҗа авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәгә (алга таба текст буенча- Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктның беренче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «5. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән зат (авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары депутатларының муниципаль вазыйфаларын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы затлардан тыш) йә җирле администрация башлыгы вазыйфасын контракт буенча башкаручы ел саен Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән вакытка тапшыра:».

1.2. 3 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы зат депутат итеп сайланганнан соң дүрт ай эчендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра, аңа вакантлы депутат мандатын тапшыру яисә даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны туктату, шулай ук белешмәләр (хисап чорына) тапшыру елыннан алдагы һәр ел өчен "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләрнең хисап чоры дәвамында башкарылган очракта. Хисап чоры дәвамында мондый алыш-бирешләр башкарылмаган очракта, күрсәтелгән зат бу хакта «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешендә каралган махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсыннан файдаланып хәбәр итү юлы белән Татарстан Республикасы Президентына хәбәр итә, «муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымта нигезендә. «Муниципаль

вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымта нигезендәге рәвеш буенча, шулай ук белешмәләр (килешү буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләрнең дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында) бирелү тәртибе турында» 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымта нигезендә каралган. Авыл җирлеге вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы зат тарафыннан имзаланган кәгазь чыганактагы хәбәрнамәнең күчермәсе тиешле муниципаль районда коррупцияне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелә һәм законнар нигезендә сакланырга тиеш.».

1.3. Нигезләмәне 7.1 пункт белән тулыландырырга, түбәндәге эчтәлектә: «7.1. Контракт буенча муниципаль вазыйфа йә җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче зат әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән сроклар тәмамланганнан соң бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Югары Кибәхуҗа
авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Мәхмүтов